| СОВЕТ<br>ЧУВАШСКО-ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЧУАШ ЧҮПРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| --- | --- |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Новое Ильмово

10 марта 2020 года № 52/2

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең коррупцион хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 16.12.2009 елдагы 432-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге Уставы нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге Советының 30.01.2013 ел, № 24/4 карары белән расланган коррупцион хокук бозуларны кылган өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә»;

2) 1.15 пунктының алтынчы абзацында «керемнәр» сүзләреннән соң «чыгымнар» сүзләрен өстәргә»;

3) 2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14_1, 15 һәм 27 статьяларында каралган түләтүләр, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә яраксызлыгы, ялында булу чорларын исәпкә алмаганда, муниципаль хезмәткәрләргә коррупцион хокук бозу кылу турында мәгълүмат кергән көннән алты айдан да соңга калмыйча һәм

коррупцион хокук бозу кылган көннән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытка җинаять эше буенча җитештерү вакыты кертелми».

4) 2.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«коррупцион хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе доклады, анда аны башкаруның факттагы шартлары һәм муниципаль хезмәткәрнең ризалыгы белән генә һәм коррупцион хокук бозу фактын тану шарты белән (ышаныч югалуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге түләтүне кулланудан тыш), язма аңлатма бирелә».

2. Коррупцион хокук бозулар кылган өчен муниципаль хезмәткәрләрне җаваплылыкка тарту мәсьәләләрен жайга сала торган муниципаль норматив хокукый актларны эшләү һәм бастырып чыгарганда әлеге карар белән эш итәргә кирәк.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яна Элмәлеа выл җирлеге Советының Законлылык һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге
башлыгы Чүпрәле муниципаль
районы Татарстан Республикасы

В.В.Землемеров